

Жаваплы һәм кирәкле эш ул киләчәк буынны тәрбияләv. Баланын доньяга карашын тәрбияләvдә балалар бакчасы тәрбиячесенен роле әйтеп бетергесез. Балалар тормышында яхшы педагог, дус һәм «икенче әни» буларлык кеше очраса - бала бик тә унды дип исәпләргә була.
Шулай, Кадошкинодагы «Теремок» дигән балалар бакчасынын уртанчылар группасында тәрбияләнгән балалар бик тә унды. Чонки алар Аәлита Халил кызы Якубова тәрбиясен алалар. Балалар да ярата vзен.
Аәлита Халил кызы бу районнын Латышовка авылы Байчуриннар педагоглар династиясенен дәвамчысы. Халил Айса улы белән Асма Усман кызы гомерләрен туган авыллары мәктәбендә балаларга белем биргәннәр. Әтисе тогәл фәннәр алып барган, директор булып эшләгән, ә әнисе рус теле һәм әдәбияты укыткан. Бу кешеләрне ничә буын латышлылар vзләренен әйдәп баручылары булып санаганнар, рәхмәт белән искә алалар. Шуна Аәлита профессиясен сайламый, ул тумыштан тоемлап яши аны; шулай укытучылар гаиләсендә тәрбияләнгән, кияvгә дә укытучылар гаиләсенә чыга. Латышовка урта мәктәбен унышлы тәмамлап, М.Е.Евсевьев педагогия институнын мәктәпкәчә тәрбия факультетында белем ала. 1987 елдан алып балалар бакчасында хезмәт итә. Бер тапкыр да тәрбияче профессиясен сайлаганга шикләнгәне дә, vкенгәне дә юк.
- Сәләтсез балалар юк, - дип ышана А.Х.Якубова. - Бvгенге группа балаларым белән мин бакча бусагасын атлаган коннән алып бергә. Традиция буенча, баланы тәрбияче мәктәпкәчә алып бара. Балаларымны яратам һәм алар бик тә сәләтлеләр. Ана-аталар белән дә бер-беребезне яхшы белеп аралашабыз. Безнен vз традицияләребез, vземнен эш системам бар. Балаларым торле характерлы һәм алар бар әйбер белән кызыксынучан. Ничек vсvләре артыннан кvзәтv - vзе бер шатлык. Алар белән һәр кон ниндидер яналык ачасын. Шунын очен дә яратам профессиямне.
Аәлит Халиловна vзенен юлы белән барган Регина кызы белән горурлана. Чонки әби-бабасы, әни-әтисе юлын дәвам итеп, логопед белгечлеген ала. Әнисе белән янәшәдә, «Теремок» балалар бакчасында, хезмәт биографиясен дә башлап жибәрә. Ә Регина, әнисе Аәлита Халил кызы белән әтисе Вагиз Максут улы Якубовлар педагоглар династиясен генә тvгел, укытучы әби-бабае Байчуриннар юлын да дәвам итә. Бу барысы да Латышовка авылы укытучылары династияләренен кочле традицияләре.

**Н.Хәлил**